Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кощаково авыл җирлеге

Кощаково авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

«14» январь, 2026 ел № 4

Татарстан Республикасы Питрәч районы Кощаково авылында урнашкан җир кишәрлекләре территориясен планлаштыру проектын раслау турында гавами тыңлаулар үткәрү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2023 елның 23 декабрендәге Татарстан Республикасы Законы нигезендә «Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 131-ТРЗ номерлы Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Кощаково авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Кощаково авыл җирлегендә гавами тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Кощаково авыл җирлеге территориясендә урнашкан җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары хокук ияләренең тормыш эшчәнлегенең уңай шартларына район халкының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатларында карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Кощаково авыл җирлеге, Кощаково авылы адресы буенча 16:33:080111:305, 16:33:080111:304 кадастр номерлары булган җир кишәрлекләре территориясен планлаштыру проектын раслау турында гавами тыңлаулар уздыруны билгеләргә.

2. Территорияне планлаштыру проекты буенча гавами тыңлаулар оештыруны һәм уздыруны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Кощаково авыл җирлеге башкарма комитетына йөкләргә.

3. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

3.1. гавами тыңлаулар үткәрү датасы һәм вакыты – 2026 елның 3 февралендә 12.00 сәгатьтә;

3.2. үткәрү вакыты -1 көн;

3.3. үткәрү урыны - Кощаково авыл мәдәният йортының тамаша залы, адресы: Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Кощаково авылы, Үзәк ур., 19 й.;

3.4. чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуга гаризалар бирү вакыты - 2026 елның 30 гыйнварена кадәр;

- язма рәвештә, эш көннәрендә көн саен 09.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр, 14.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр Кощаково авыл җирлеге башкарма комитетына

түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Кощаково авылы, Комсомол урамы, 13 йорт, гражданнар өчен мәҗбүри рәвештә: фамилиясе, исеме, атасының исеме, теркәлү адресы күрсәтелгән яшәү урыны, эш урыннары һәм биләгән вазыйфалары, элемтә телефоннары; гражданнар төркеме өчен-фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре, нинди дә булса иҗтимагый оешмалардан яисә берләшмәләрдән булулары (әгәр булса), яшәү урынын теркәү адреслары, контакт телефоннары, юридик затлар өчен – оешма бланкында, җитәкченең фамилиясен, исемен, атасының исемен күрсәтеп.

4. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге башкарма комитетына:

4.1. Гавами тыңлаулар уздыру турында мәгълүматны «Вперед» («Алга») район газетасында, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Кощаково авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга;

4.2. Территорияне планлаштыру проекты буенча билгеләнгән тәртип нигезендә һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга.

5. Гавами тыңлауларга чыгарылган территорияне планлаштыру проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кызыксынган затлар тарафыннан Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге башкарма комитетына эш көннәрендә мәгълүмат басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) мизгелдән 8 сәгать 00 минуттан 12 сәгать 00 минутка кадәр, 13 сәгать 00 минуттан 16 сәгать 00 минутка кадәр язма рәвештә тапшырылырга мөмкин. 2026 елның 30 январендә (шул исәптән), Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Кощаково авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы, адресы: (422774, Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Кощаково авылы, Комсомол ур., 13 йорт).

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Кощаково авыл җирлеге башлыгы З.Н. Саттарова